ГЛАВА ЯМБУЛАТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯМБУЛАТ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

25.10.2025 №2

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авылы җирлеге Крестниково авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлегенең Крестниково авылы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме? " дигән сорау буенча 2025 елның 25 октябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде: белән:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту:

«ӘЙЕ» «ЮК»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә җыенда катнашкан 149 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 12 кеше. Кворум юк.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге Крестниково авылында гражданнар җыенын булмады дип таныырга.

2. Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлегенең Крестниково авылындагы халык җыены нәтиҗәләрен Ямбулат авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Ямбулат авыл җирлеге башлыгы М.А.Жестков